

ҖИР ЙӨЗЕНДӘ ТЫНЫЧЛЫК ,ДУСЛЫК, МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК, ГАДЕЛЛЕК БУЛСЫН!

№2 Ноябрь Декабрь
2020 нче ел

# МӘКТӘП СУЛЫШЫ

## Бу санда

*“Сәйяр” балалар һәм яшүсмерләр республика театр фестивале*



*Татар теленең киләчәк язмышы олимпиадаларда сынала*




*Татар халкының милли ризыгы-өчпочмак пешерү*



## “Сәяр” йолдызлары-2020

Укучыларда сәнгатьле уку күнекмәләрен формалаштыруның төрле юллары бар. Шуларның берсе - баланы сәхнәгә тарту. Сәхнә баланы шәхес буларак формалаштыруда ярдәм итә. Беренчедән, бала ана телендә матур һәм дөрес итеп сөйләшергә өйрәнә. Икенчедән, укучыда аудитория алдында үзен иркен тоту, югалып калмау, кыю булу кебек матур сыйфатлар тәрбияләнә.

Ата-аналар белән элемтәне ныгыту максатыннан, Ютазы районының 2 нче санлы Урыссу урта мәктәбендә оештырылган “Ямьле балачак” түркеме 2015 нче елдан эшләп килә. Түркемдә төрле яшьтәге укучылар катнаша. 2015 нче елдан түркемнең җитәкчесе туган (татар) тел укытучысы Юсупова Руфина Рим кызы булса, 2019 нчы елдан Хөсәенова Лилия Тәкъсин кызы белән берлектә нәтиҗәле эш алып барабыз.

Әсәрләрне сәхнәләштерү, балаларның артистлык сәләтләрен үстерү күп көч таләп итә торган процесс. Моның өчен иң беренче күпкырлы һәм күптөрле әзерлек эшләре алып баруы зарур. Әсәрләрне сәхнәләштергәндә беренче чиратта үзебез һәм балалар белән эшләү өчен план төзүдән башлыйбыз: әсәрләр балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып сайлана; балалар әкият белән таныштырыла; геройларның кылган гамәлләренә, үз-үзләрен тотышларына анализ ясала һәм бәя бирелә. Алга таба әкият өчен кирәкле булган атрибутлар, костюмнар, декорациялар зәвык белән әзерлибез. Осталыкларын исәпкә алып балаларны рольләргә бүләбез. Укучылар төрле сәхнә әсәрләре белән мәктәптә, район мәдәният йортында, республикабызның төрле шәһәрләрендә нәтиҗәле чыгыш ясыйлар.

# “Сәйяр” балалар һәм яшүсмерләр республика театр фестивале



20 декабрь көнне «Сәйяр» Республика балалар һәм яшүсмерләр театр фестиваленең муниципаль туры узды. Мәктәбебезнең “Ямьле балачак” театр коллективы Гаяз Исхакыйның "Кәҗүл читек" әсәрен күрсәтте. Рольләргә килгәндә, Мулла ролен Садриев Раиль, Әти–Гайсин Равил, Әни – Ногманова Диана, Әби-Петрова Снежана, Рәбига-Җәләева Әдилә, Әхмәдулла ролен Шәрәфиева Эвелина башкарды.

Шулай итеп, укучыларыбызның чыгышы беренче урынга лаек булды. Яшь артистларыбызга алга таба да иҗади уңышлар телибез.

Сүз уңаеннан, «Сәйяр» республикакүләм театр фестивале бәйгесе 2014-2020 елларга караган Татарстан Республикасында дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү программасы нигезендә Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татмедиа» Ачык акционерлык җәмгыяте, «Татмедиа» филиалы «Салават күпере» балалар һәм «Сәхнә» театр журналлары тарафыннан үткәрелә.

***Тәмле булсын***

***Бүген бәйрәм табынына өчпочмак әзерлибез. Өчпочмак** – татар халкының табын күрке булган милли ризыкларының берсе.*

**Өчпочмак:**
**Камыр ясау өчен:** 500 грамм он, 260 миллилитр сөт, 15 грамм чүпрә, бер бал кашыгы тоз, 60грамм ак май, дүрт аш кашыгы көнбагыш мае һәм ике тавык йомыркасы (өсләренә сөртү өчен).

**Эчлеге өчен:** 400 грамм ит, 450 грамм бәрәңге, бер баш суган (100-120 грамм), 50 миллилитр тавык шулпасы, дүрт аш кашыгы көнбагыш мае, тоз һәм кирәгенчә борыч.





Өчпочмакны зуррак итеп тә, кечерәк итеп тә ясарга мөмкин.
Камырны, куна өстенә салып бераз баскач, өч бармак калынлыгындагы таяк кебек итеп тәгәрәтәләр, аны,90 г зурлыгындагы кисәкләргә бүлеп,ике кул белән йомарламнар ясыйлар һәм чынаяк тәлинкәсе зурлыгында, 4-5 мм калынлыкта итеп җәяләр, уртасына өеп эчлек салалар. Камырны як-яктан күтәреп, өчпочмаклап ябыштыралар да матур итеп сырлыйлар.
Урта бер җирдә бармак сыярлык тишек калдыралар. Әгәр теләсәң, өчпочмак өстенә тугланган йомырка сөртергә була.





***Бәйрәм сыебыз әзер! Ашларыгыз тәмле булсын!***



Бүген бездә кунакта

# Татар теленең киләчәк язмышы олимпиадаларда сынала











Олимпиада ул – укучының көчен сынап карар өчен оештырыла торган чара, фән буенча булган белемнәрен күрсәтергә менә дигән мөмкинчелек. Әзерләнү моменты гына да күпме яңа мәгълүмат, белем бирә. Җиңү түгел, ә шул алган белемнәр укучы тормышына йогынты ясый, ярдәм итә бит. Мәктәбебез укучылары, менә шул хакыйкатьне аңлап, бик теләп татар теле фәненнән олимпиадаларда катнашалар. Декабрь аенда татар теле һәм әдәбиятыннан республика олимпиадасының муниципаль туры узды. Районыбызның барлык мәктәпләреннән дә бик талантлы укучылар катнаштылар. Район мәгариф бүлеге тарафыннан төзелгән олимпиада тикшерү комиссиясе эшләрне җентекләп карады, бәяләде, укучыларыбызның фән буенча белемнәре югары дигән нәтиҗәгә килде.

Мәктәбебездән дә татар теле белән кызыксынучы, зирәк, тырыш укучыларыбыз катнаштылар һәм җиңү яуладылар. Татар төркемендә белем алучы укучылар арасында 9 нчы сыйныф укучысы Шакирова Элина – призер, 8 нче сыйныф укучылары Гайсин Равил- җиңүче, Әхмәтвәлиева Элина- призер, 4 нче сыйныф укучысы Сөләйманова Амира –призер. Рус төркемендә белем алучылар арасында Кощиенко Карина җиңүче булды.



*Бүгенге иҗатыбыз яңа елга багышлана.*

# *Балалар иҗаты*





Шангараев Эмиль,
3 нче Б сыйныфы укучысы

Грудинина Ралина,
4 нче А сыйныфы укучысы









Ластовская Александра,
3 нче Б сыйныфы укучысы

Петрова Алиса,
4 нче А сыйныфы укучысы

Желенков Арсений,
4 нче А сыйныфы укучысы

# Ә син беләидеңме?



## Яңа ел уенчыгы

Чыршы уенчыгының, тарихы 1513 елда немец галиме Мартин Лютердан башланган дип саныйлар. Бер кич бу абзый урамнан кайтып барганда йолдызлар тулы күк йөзен күреп ала, ул чыршы очларындагы якты утларга сокланып туя алмый. Өенә кайткач ул бер кечкенә чыршыны шәмнәр белән бизи һәм баш очына йолдыз куя.

19 нчы гасырда бу гадәт Англия, Австрия, Чехия һәм башка илләрдә киң тарала.Ком онынннан пешерелгән уенчыкларны аеруча яратып эшлиләр.



20 нче гасыр башында Россиядә чыршы уенчыкларын Клин шәһәрендә эшли башлыйлар. Дару җиһазлары заводында беренче тапкыр пыяладан шарлар һәм мәрҗәннәр өреп ясыйлар. Түбән Новгород шулай ук чыршы уенчыгы һөнәрчелеген үстергән шәһәр санала.

Пыяладан кала уенчыкларны катыргы кәгазьдән дә ясаганнар. Шулай ук революциягә кадәр кәгазь битлекурчакларга тукыма, бисер, мәрҗәннәрдән киеп ясап чыршыга элгәннәр. Соңрак фарфор һәм мамык уенчыклар барлыкка килгән. Чыршылар тарихи чорга карап бизәлә.Мәсәлән, сугыш елларында бәйрәм агачы "солдат", "танк", "санитар-этләр" h.б. белән бизәлгән.

Бүгенге көндә һәркем чыршы бизәү ысулын үзе сайлый. Россиядә төрле милләт кешеләре дус-тату булып яшиләр.





**Гәҗитне басмага әзерләделәр:**

6 нчы сыйныф укучылары

Җитәкчеләре: Хөсәенова Л.Т.

***Сездән язмалар көтеп калабыз!***